**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

**2022 елның 02 ноябре** **2664 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш районының Олы Кабан поселогында «Аэросити»4 чират территориясен үзләштерү концепциясе» планлаштыру проектын раслау турында» 2022 елның 18 февралендәге 339 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында.**

Капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Лаеш районының Олы Кабан поселогында «Аэросити»4 чират территориясен үзләштерү концепциясе» планлаштыру проектына үзгәрешләр кертергә, түбәндәге пунктларга өстәп:

- Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авыл җирлеге, Олы Кабан авылы адресы буенча урнашкан, аренда хокукында Гусев Александр Владимирович карамагындагы (Аренда шартнамәсе №34/2512/2513/115/114/БК, 13.11.2020ел), кадастр номеры 16:24:160101:2512 булган, 893 кв.м. мәйданлы һәм кадастр номеры 16:24:160101:2513 булган, 897 кв.м. мәйданлы җир кишәрлекләрен берләштерү нәтиҗәсендә 1790 кв.м мәйданлы ЗУ1 кадастр номерлы бер җир кишәрлеге барлыкка килә.

**Җир кишәрлекләре категориясе:** Торак пунктлар җирләре

**Рөхсәт ителгән куллану:** Торак төзелеше

- Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авыл җирлеге, Олы Кабан авылы, . Звездная ур. ЗУ 12 адресы буенча урнашкан, аренда хокукында Николаев Алексей Иванович карамагындагы (Аренда шартнамәсе №34/2510/117/БК 09.09.2020ел., Аренда шартнамәсе №34/2511/116/БК 15.04.2020ел), кадастр номеры 16:24:160101:2510 булган, 894 кв.м. мәйданлы һәм

кадастр номеры 16:24:160101:2511 булган, 901кв.м. мәйданлы җир кишәрлекләрен берләштерү нәтиҗәсендә 1795 кв.м мәйданлы ЗУ1 кадастр номерлы бер җир кишәрлеге барлыкка килә.

**Җир кишәрлекләре категориясе:** Торак пунктлар җирләре

**Рөхсәт ителгән куллану:** Торак төзелеше

3. Әлеге карарны "Кама ягы"(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**